Кисәкчәләр турында беренче мәгълүмат 3 нче сыйныфта бирелә. Кисәкчәләр (да, дә, та, тә, гына, генә, кына, кенә, ук, үк, ич, бит). Аларның дөрес язылышы. Кисәкчәләр сүз яки җөмләгә төрле төсмер өстәү өчен кулланылуы ачыклана. Кисәкчәләр аерым торганда мәгънә белдерми. Бик күп кисәкчә күп мәгънәле була,һәм аларның мәгънә төсмерләре нинди сүзгә иярүләренә, кайсы урында килүләренә, җөмлә төзелешенә, аның интонациясенә карап үзгәрә.

## *Союзы*

*Повторение знаний , изученных в 1-3 классах. Союз –вспомогательная часть речи, поэтому главное значение союзов связь слов в предложении. Наблюдение того, как союзы используются с именами существительными и местоимениями в разных падежах. Союз – это одна из грамматических категорий.*

## Бәйлекләр

1-3 нче сыйныфларда өйрәнгәннәрне кабатлау. Бәйлек- ярдәмче сүз, шуңа күрә, төшенчәдә төп урынны бәйлекнең функциясе, үтәгән хезмәте алып тора: бәйлекләр сүзләрне бәйлиләр. Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүенә күзәтүләр. Бәйлек төшенчәсе грамматик категория итеп аңлатыла.

## *Словосочетание*

*В 4 классе даетсяболее глубокое понятие словосочетания: объяснение различия словосочетания и сочетания слов, как они образуются, пути происхождения, наличие в словосочетаниях главного и зависимого слова.*

## Сүзтезмә

4 нче сыйныфта сүзтезмәләргә шактый эзлекле мәгълүмат бирү күздә тотыла : сүзтезмә һәм тезмә сүзләр арасындагы аерманы аңлату, сүзтезмәләрнең барлыкка килү юлларын ныгыту, сүзтезмәдәге ияртүче һәм ияртүче сүз турында белемнәрне тирәнәйтү.

***Предложение***

*Главные члены предложения. Отличие главных членов от второстепенных. Связь слов в предложении. Определение подлежащего и сказуемого. Распространенные и нераспространенные предложения. Второстепенные члены предложения. Определение. Дать понятие определения, которое часто выражается именем.*

**Җөмлә**

Җөмләнең баш кисәкләре. Баш һәм иярчен кисәкләрнең аермасы. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Ия белән хәбәр билгеләмәсе . Җыйнак һәм җәенке җөмләләр . Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч.. Аергычка билгеләмә бирү һәм аның сыйфат белән белдерелүе .

***Однородные члены предложения***

*Однородные члены предложения, интонация перечисления, связь слов с помощью предлогов, знаки препинания между однородным членами предложения. Предложения с однородными подлежащими и однородными сказуемыми. Однородные члены предложения, знаки препинания в данных предложениях. Дать понятие обращения. Научить ставить знаки препинания при обращении. Простые и сложные предложения. Сложные предложения состоящие из 2-3 простых предложений. Сложносочиненные сложные предложения, знаки препинания в данных предложениях.*

**Җөмләнең тиңдәш кисәкләре**

Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен һәм тиңдәш кисәкләрнең үзара санау интонациясен, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнешен төшендерү, тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләренең куелышын аңлату. Тиңдәш ияле һәм тиңдәш хәбәрле җөмләләр. Тиңдәш кисәкләр арасында **һәм, я, да-дә, та-тә, ә, ләкин** теркәгечләре, тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.Эндәш сүзләр турында төшенчә бирү. Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләрен куярга өйрәтү. Гади һәм кушма җөмләләр турында төшенчә бирү. Составында 2-3 гади җөмлә булган кушма җөмләләр**.** Тезмә кушма җөмләләрдә **һәм, ә, ләкин, әмма** теркәгечләре, алар янында тыныш билгеләре.

***Развитие связной речи***

*Речь, ее роль в жизни человека. Использование в речи текстов на определенную тему (описание, повествование, рассуждение) , развитие монологической речи. Текст. Признаки текста. Смысловая связь предложений в тексте. Название текста. Преемственность предложений в тексте. Связь частей текста, понятие красной строки. Дать название тексту, определить часть текста и предложения, коррекция текста. Составление плана текста. Составление текста по данному плану. Тексты описание и повествование , их особенности. Поздравление и письмо. Составление текста , соблюдая все правила орфографии и пунктуации, использование в текстах синонимов и антонимов. Знакомство с изложением и сочинением ( не заучивая определения) : писать изложение и сочинение, используя весь или часть предложенного текста, повествование –описание.*

**Бәйләнешле сөйләм**

Сөйләм, аның тормыштагы роле. Билгеле бер темага караган төрле (сурәтләү, хикәяләү характерындагы) сөйләм текстлары кулланып, телдән монологик сөйләмне гамәли яктан үзләштерү. Текст. Текст билгеләре. Тексттагы җөмләләрнең мәгънәви бердәмлеге.Текстка исем бирү.Тексттагы җөмләләрнең эзлеклелеге. Текст кисәкләренең (өлешләренең) эзлеклелеге, кызыл юл турында төшенчә. Текстка исем бирү, җөмлә һәм текст кисәкләрен билгеләү, җөмлә һәм текст кисәкләре эзлеклелеген төзәтү. Текстның планын төзү. Бирелгән план буенча үз текстыңны төзү. Сурәтләү һәм хикәяләү характерындагы текстлар, аларның үзенчәлекләре. Котлау тексты һәм хат язу. Язма сөйләмнең төгәллеген, дөреслеген һәм сәнгатьлелеген саклап, үз

текстыңны төзү һәм бирелгән текстларны тикшереп төзәтү, текстта синонимнар, антонимнар куллану. Изложение һәм сочинениенең төп төрләре белән танышу (билгеләмәләрен ятламыйча): бирелгән текстны тулысынча файдаланып яки аерым урыннарын (сүзләрен) сайлап алып языла торган изложение, сочинение элементлары булган изложение, хикәяләү-сурәтләү рәвешендәге сочинение һ.б.

## Тематическое планирование
## Тематик планлаштыру

| *Тема раздела*<br>**Бүлекнең темасы** | *Количество часов*<br>**Сәгать саны** | *Основные виды деятельности учащихся*<br>**Укучыларның төп эшчәнлелек төрләре** |
|---|---|---|
| **1 класс**<br>**1 нче сыйныф** | | |
| ***Добукварный период***<br><br>**Грамотага әзерлек чоры** | 4 | *Усвоение гигиенических требований при письме, воспитывать привычку к постоянному соблюдению правил. Общее представление об устной и письменной речи.. Умение красиво говорить, читать и писать.*<br>*С помощью графических схем можно разделить речь на предложения, предложения, разобрать слова на предложения и звуки.*<br>Язу гигиенасы кагыйдәләре белән таныштыру, кагыйдәләрне даими үтәү гадәте тәрбияләү.Кешеләрнең әйтеп һәм язып сөйләшүләрен гомуми күзаллау. Матур итеп сөйләшә, укый һәм яза белү кирәклеген аңлау.<br>График схемалар ярдәмендә сөйләмне — җөмләләргә, җөмләне сүзләргә аеру, сүзләрне иҗек һәм авазларга таркату. |
| ***Букварный период***<br><br>**Әлифба чоры** | 37 | *Ознакомление и каллиграфическое правописание всех заглавных и строчных букв с основными линиями их соединения. Указание звуков соответствующими письменными буквами в слове. Осознание необходимости соблюдения при письме таких графических средств, как интервал между словами, проставление знака переноса между ними. Списывание с печатного и письменного текста слова и небольших предложений.*<br>*Списывание слов, предложений в соответствии с изучаемой темой. Сравнение написанных букв с предложенным учителем образцом. Письмо предложений состоящих из 3-4 слов, не имеющих различий в произношении и написании .*<br>Барлык баш һәм юл хәрефләренең язылышы һәм аларның тоташтыруның төп сызыклары белән таныштыру һәм каллиграфик дөрес язарга өйрәнү. Авазларны сүздә тиешле язма хәрефләр белән күрсәтү. Сүздәге хәрефләрне, аларны тоташтырган сызыкларын өзмичә ритмик язуны(ас-ос) |

| | | |
|---|---|---|
| | | булдыру, дәфтәр юлларына хәрефләрне һәм сүзләрне, тигез ара калдырып, тигез, дөрес урнаштыралар. Башта укытучы белән иҗек–аваз анализы ясаганнан соң, тора бара мөстәкыйль рәвештә сүзләр, җөмләләр язу.<br>Башта язмача, аннары басмача үрнәкләрдән сүзләр, җөмләләр күчереп язу. Үрнәк текст белән чагыштырып карау һәм сүзләрне иҗекләп орфографик уку ярдәмендә дәфтәргә язылганнарның дөреслеген тикшерү. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүзләрне, шундый өч-дүрт сүздән торган җөмләләрне әйтеп язу. |
| ***Послебукварный период***<br>**Әлифбадан соңгы чор** | 4 | *Правильное написание алфавита, чтение.Написание предложений отдельными словами. Правильно переписать текст.*<br>Алфавитны дөрес язу,уку.Аерым сүзләр белән җөмләләр төзеп язу. Текстны дөрес итеп күчереп язу. |
| ***Звуки и буквы***<br><br><br><br><br><br>**Авазлар һәм хәрефләр** | 4 | *Умение различать звонкие и звонкие звуки. Согласование звуков . Правильное использование букв ь и ъ в письме. Определение звуко – буквенной состав в словах с буквами е, ю, я. Правильно читать и писать стихи и слова. Совершенствовать разделение слов на слоги, перенос их с одной строки на другую. Научиться читать слово с соответствующим ударением. Ознакомление с правилами правильного написания и их применением: запомнить, что буквы О, о пишутся только в первом слоге татарского слова.*<br>Сузык һәм тартык авазларны аера белү. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышын камилләштерү. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуын истә калдыру. Язуда **ъ** һәм **ь** хәрефләрен **дөрес** куллану. **Е – ё**, **ю**, **я** хәрефләре булган сүзләрдә аваз һәм хәреф бәйләнешен билгеләү. Иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес уку һәм язуны ныгыту. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан юлга күчерүне камилләштерү. Сүзне тиешле басым белән укырга өйрәнү. Дөрес язу кагыйдәләре һәм аларның кулланылышы белән танышу: **о**, **ө** хәрефләренең татар сүзләренең беренче иҗегендә генә язылуын истә калдыру. |
| ***Синтаксис***<br><br><br>**Синтаксис** | 3 | *Умение находить границы предложений. Написание слова в начале предложения с заглавной буквы, совершенствование правильной постановки точки, вопроса и восклицательных знаков в конце предложения.*<br>Җөмлә чикләрен таба белү. Җөмлә башындагы сүзне баш хәреф белән язу, җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләрен дөрес куюны камилләштерү. |
| ***Морфология*** | 3 | *Знакомство со словами обозначающие названия предмета. Разъяснение их смысла, вопросы; Собственные и нарицательные имена и их написания.*<br>*Знакомство со словами, выражающими признак предмета, его смыслом и использованием в речи.* |

| | | |
|---|---|---|
| **Морфология** | | *Знакомство со словами, выражающими действия предметов.*<br>Предметны белдергән сүзләр белән танышу. Аларның мәгънәләрен аңлату, сорауларын әйтү;<br>Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр һәм аларның язылышын камилләштерү. Исемнәр янында кулланыла торган ярдәмче сүзләр- бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән танышу.<br>Предметның билгесен белдергән сүзләр, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы белән танышу.<br>Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр белән танышу. |
| ***Орфография***<br><br>**Орфография** | 6 | *Умение находить в слове орфограммы, различать их и правильно писать. Написание заглавной буквы в первом слове предложения,именах людей, фамилиях людей,кличках животных,географических названиях.*<br>Сүздә орфограмманы күрү,аерып алу, дөрес язу, шул орфограммага сүзләр табу. Җөмләнең беренче сүзендә,кеше исемнәрендә, кеше фамилияләрендә,хайван кушаматларында,географик атамаларда баш хәреф язу. |
| ***Развитие речи***<br><br>**Бәйләнешле сөйләм үстерү** | 5 | *Правописание небольших текстов ( без пропуска букв и слогов, без замены мест ), слов.. Произношение и написание предложений. Умение писать стихи, пословицы, поговорки по памяти. Передача содержания прослушанного или прочитанного в изложении. Написание небольших по своим свойствам текстов (сочинений).*<br>Кечкенә текстларны дөрес итеп ( иҗек һәм хәрефләрне төшереп калдырмыйча, урыннарын алыштырмыйча ), сүзләп күчереп язу. Әйтелеше белән язылышы туры килгән сүзләрдән төзелгән җөмләләрне ишетеп язу. Шигырь, мәкаль, әйтем һәм табышмакларны хәтер диктанты итеп язарга өйрәнү. Тыңлаганның яки укыганның эчтәлеген изложение итеп язарга өйрәнү. Үзлекләреннән зур булмаган текстлар (сочинение) иҗат итеп язу. |
| ***Всего* /Барлыгы** | **66** | |
| | **2 класс/2 нче сыйныф** | |
| ***Фонетика и орфоэпия***<br><br>**Фонетика һәм орфоэпия** | 30 | *Понимание разницы между звуком и буквой; характеристика звуков родного языка: твердые / мягкие звуки; парные/непарные, звонкие/ глухие согласные;*<br>*Обнаружение звуков речи с ударением и безударными гласными. Характеристика звуков речи и ящика.*<br>*Разделять слово на слоги, определять количество слогов. Использование правил, изученных при переписывании.*<br>Аваз белән хәреф арасындагы аерманы аңлау; туган тел авазларына характеристика бирү: калын /нечкә сузыклар; парлы/парсыз, яңгырау/ саңгырау тартыклар;<br>Сүздәге басымлы һәм басымсыз авазларны табу. Сузык һәм тартык авазларга характеристика |

| | | |
|---|---|---|
| | | бирү.<br>Татар теленә генә хас булган авазларны дөрес әйтү. Сүзне иҗекләргә аеру, иҗекләр санын билгеләү. Күчереп язганда һәм әйтеп яздырганда өйрәнелгән кагыйдәләрне куллану. |
| **Графика** | 2 | *Различать звуки и  буквы: буква как знак звука. Знание порядка букв в алфавите, использование алфавита для размещения слов в алфавитном порядке и при поиске необходимой информации.*<br>Аваз һәм хәрефләрне аеру: аваз билгесе буларак хәреф. Алфавиттагы хәрефләр тәртибен белү, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру өчен һәм кирәкле мәгълүматны тапканда алфавиттан файдалану. |
| ***Слово***<br><br><br><br><br><br>**Сүз** | 22 | *Найти однокоренные слова из текста. Различать однокоренные слова и обозначать корень. Разделять однокоренные слова и словоформы. Найти основную часть слова. Кто? Что? знание имен, отвечающих на вопросы. Умение находить  имена собственные и нарицательные.*<br>*Знание прилагательных, отвечающих на вопросы какой?. Умение правильно использовать прилагательныхв речи.?Уметь распознавать и правильно использовать в речи глаголы, отвечающие на  вопросы Что делает? Что делают?  Что сделают?*<br>Тексттан  тамырдаш сүзләрне табу. Тамырдаш сүзләрне аеру  һәм тамырын билгеләү. Тамырдаш сүзләрне һәм сүз формаларны аеру. Сүзнең төп өлешен табу. Кем? Нәрсә? сорауларына җавап бирә торган исемнәрне белү. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәрен танып белү.<br>Нинди? Кайсы? сорауларына җавап бирә торган сыйфатларны  танып белү. Сөйләмдә сыйфатларны дөрес куллана белү. Нишли? Нишлиләр? Нишләр? Нишләрләр? сорауларына җавап бирә торган фигыльләрне тану һәм сөйләмдә дөрес куллана белү. |
| ***Предложение***<br><br><br><br><br><br>**Җөмлә** | 4 | *Предложение состоит из группы слов, определяющих ее границы. Создание предложений из слов. Найти главные и второстепенные членыпредложения. Создание простых  и сложных предложений.  Регулировка связи слов в предложении. Из приведенных слов составить предложение. Найти все словосочетания в предложении.  Разделять сложные и простые предложения. Цель высказывания и определение трех видов предложения по эмоциональному оформлению.*<br>Җөмләне сүзләр төркеменнән аеру, аның чикләрен билгеләү. Сүзләрдән җөмләләр төзү. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен табу. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр төзү.  Җөмләдәге сүзләр бәйләнешен көйләү. Бирелгән сүзләрдән җөмлә төзү. Җөмләдәге барлык сүзтезмәләрне табу.  Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне аеру. Әйтү максаты һәм эмоциональ бизәге буенча җөмләнең өч төрен билгеләү. |
| ***Развитие речи*** | 10 | *Определение темы и основной части текста. Присвоение темы  тексту, приведение его имени в соответствие с текстом. Составление рассказа по рисунку с помощью предложенной в вводной* |

| | | |
|---|---|---|
| **Бәйләнешле сөйләм** | | *части и опорных слов.*<br>*Составление плана текста и его использование в устной речи и письменном повествовании. Определение смысловых частей текста. Составление рассказа на заданную тему с использованием различных типов речи: описание, повествование, мышление; закрепление основных правил речевого этикета, речевой литературы (при общении с учащимися и взрослыми); освоение основных правил литературной речи на основе изученного словарного богатства.*<br>Текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү. Текстка исем бирү, текст белән аның исемен туры китерү. Тәкъдим ителгән башлам өлеше һәм терәк сүзләр ярдәмендә рәсем буенча хикәя төзү.<br>Текстның планын төзү һәм аны телдән сөйләгәндә һәм язмача хикәяләгәндә куллану. Текстта мәгънәле кисәкләрне билгеләү. Билгеләнгән темага, төрле сөйләм типларын кулланып, хикәя төзү: тасвирлау, хикәяләү, фикерләү; сөйләм этикетының, сөйләм әдәбенең (укучылар һәм өлкәннәр белән аралашканда) төп кагыйдәләрен ныгыту; өйрәнелгән сүзлек байлыгы нигезендә әдәби сөйләмнең төп кагыйдәләрен үзләштерү. |
| ***Всего* /Барлыгы** | **68** | |
| **3 класс<br>3 нче сыйныф** | | |
| ***Фонетика и орфопия***<br><br><br><br><br>**Фонетика һәм орфоэпия** | 4 | *Распознавать звонкие, глухие согласные и гласные звуки; находить в словах изученные орфограммы и объяснять написание слов, использовать орфографические словари.*<br>*Делить слова на слоги и определить их количество. Перенос слов по слогам. Находить и исправить ошибки, допущенные при переносе слов с одной строки на другую. Использовать знание алфавита в работе с орфографическим и орфоэпическим словарями.*<br>Яңгырау, саңгырау тартыкларны һәм сузык авазларны танып белү; өйрәнгән орфограммаларны табу һәм сүзнең дөрес язылышын аңлату, орфографик сүзлекләр куллану.<br>Сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм аларның санын билгеләү. Иҗекләргә бүлеп, сүзләрне юлдан-юлга күчерү. Сүзләрне юлдан-юлга күчергәндә ясалган хаталарны төзәтә белү.<br>Орфографик һәм орфоэпик сүзлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалану. |
| ***Лексика. Слово***<br><br><br><br>**Лексика. Сүз** | 8 | *Различать однозначные и многозначные слова, прямое и переносное значения слова, наблюдать за использованием в тексте, в собственной речи слов в переносном значении*<br>*Отличать однокоренные слова от синонимов и омонимов. Находить в тексте синонимы и антонимы.*<br>Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләрне, сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен танып белү; текстларда, үз сөйләмендә күчерелмә мәгънәле сүзләрне куллана белү. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Тамырдаш сүзләрне синонимнардан һәм омонимнардан аера белү. Теksттан синоним һәм антонимнарны билгеләү. |
| ***Состав слова и словообразование***<br><br><br><br>**Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы** | 7 | *Членить слова на корень и аффикс. Отличать словообразовательные аффиксы от словоизменяющих аффиксов.*<br>*Отличать однокоренные слова от синонимов и омонимов.*<br>*Различать способы словообразования слов.*<br>Сүзләрне тамыр һәм кушымчаларга аеру.<br>Тамырдаш сүзләрне билгели алу. Сүз ясалыш ысулларын танып белү. |
| **Морфология**<br>***Имя существительное***<br><br><br><br>**Исем** | 37<br>15 | *Различать части речи: существительное, прилагательное, местоимение, глагол.*<br>*Распознавать одушевлённые и неодушевлённые, собственные и нарицательные имена существительные; изменять существительные по числам и падежам; различать названия падежей.*<br>Исем, сыйфат, алмашлык, фигыль сүз төркемнәрен танып белү.<br>Җанлы һәм җансыз, ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне тану; исемнәрне килеш, сан белән төрләндерү, килешләрнең исемнәрен дөрес әйтү. |
| ***Глагол***<br><br>**Фигыль** | 11 | *Изменять глаголы по временам и числам. Спрягать глаголы изъявительного наклонения настоящего, прошедшего и будущего времени.*<br>Фигыльләрне заман, зат-сан белән төрләндерү. Хәзерге, үткән, киләчәк заман хикәя фигыльләрне зат-сан белән төрләндерү. |
| **Сыйфат**<br>***Имя прилагательное*** | 7 | *Различать имена прилагательные, правильно употреблять в речи формы степеней сравнения.*<br>Сыйфатларны таный алу, сыйфат дәрәҗәләрен сөйләмдә дөрес куллану. |
| ***Местоимение***<br>**Алмашлык** | 2 | *Просклонять личные местоимения. Различать падежные формы личных местоимений*<br>Зат алмашлыкларын килеш белән төрләндерү. Кушымчаларына карап, зат алмашлыкларының кайсы килешкә каравын билгеләү |
| ***Частицы***<br>**Кисәкчә** | 1 | *Различать частицы да, дә, та, тә от аффиксов местно-временного падежа –да, -дә, -та, -тә.*да, дә, та, тә кисәкчәләрен –да, -дә, -та, -тә урын-вакыт килеше кушымчаларыннан аера белү. |
| ***Послелоги***<br>**Бәйлекләр** | 1 | *Употреблять послелогов с именами существительными и местоимениями в разных падежах.*<br>Бәйлекләрне исемнәр, алмашлыклар белән төрле килешләрдә куллану. |
| **Синтаксис**<br>***Предложение***<br>**Җөмлә** | 5 | *Определять члены предложения: главные (подлежащее и сказуемое), второстепенные. Находить главные члены предложения*<br>Җөмләнең баш(ия, хәбәр), иярчен кисәкләрен билгеләү. Җөмләнең баш кисәкләрен табу. |
| ***Словосочетание*** | 2 | *Различать предложения, словосочетания, слова, главного и зависимого слова в словосочетании* |

| | | |
|---|---|---|
| **Сүтезмә** | | Җөмлә, сүтезмә, сүзне, сүтезмәдәге ияртүче, иярүче сүзләрне аера белү. |
| ***Развитие речи***<br><br><br><br><br>**Сөйләм үстерү** | 5 | *Владеть нормами речевого этикета в общении со сверстниками и взрослыми.*<br>*Знать: понятия «текст», «абзац», «план текста»; что значит начало и окончание текста, Составлять план к заданным текстам, выделять абзацы, находить связь предложений в тексте, сочинять тексты разных видов по плану. Различать понятия «текст-описание», «текст-повествование».*<br>Яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашканда сөйләм этикеты нормаларына ия булу. “Текст”, “абзац”,“текст планы”; текстның башы һәм ахыры төшенчәләрен белү. Бирелгән текстларга план төзү, абзацларны билгеләү, текsттагы җөмләләрнең бәйләнешен билгеләү. |
| ***Всего*** **/Барлыгы** | **68** | |
| | **4 класс**<br>**4 нче сыйныф** | |
| ***Повторение изученного в 1-3 классах***<br>**1-3 классларда өйрәнгәннәрне кабатлау** | 4 | *Повторить материал по фонетике, морфологии и синтаксису. Звуки и буквы, их отличие, гласные и согласные звуки, правописание и произношение отдельных звуков и букв. Строение сло , части речи. Повторить материал о предложении и его видах.*<br>Фонетика,морфология һәм синтаксистан үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтүне күздә тоту. Фонетикадан аваз һәм хәреф, алар арасындагы аерма, тартык һәм сузык авазлар, аерым авазларның дөрес әйтелешен һәм язылышын өйрәнү. Морфология буенча сүз төзелеше һәм аерым сүз төркемнәре искә төшерү. Синтаксистан җөмлә һәм аның төрләре искә төшерү. |
| ***Слово. Богатство языка. Лексическое значение слова***<br>**Сүз. Телнең сүзлек байлыгы. Сүзнең лексик мәгънәсе.** | 7 | *Повторить знания о слове и его значении, о однозначных и многозначных словах, заимствованных словах, синонимах, антонимах,омонимах. Применять полученные знания на практике. Закрепить умения работать с разными словарями и формами работы.*<br>Сүз һәм аның мәгънәсен, бер генә мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләрне, алынма сүзләрне, синоним,антоним, омонимнарны искә төшерү. Бу белемнәрне гамәли сынап карарга өйрәнү. Төрле сүзлекләр белән эшләү күнекмәләрен ныгыту. |
| ***Строение слова***<br><br>**Сүз төзелеше** | 7 | *Познакомить с сложными, парными, составными словами, их строением, особенностями слов,заимствованных из русского языка. Научиться делать анализ строения слова.*<br>Ясалма, кушма,парлы, тезмә сүзләрнең ясалышы һәм язылышы, рус теленнән татар теленә кергән алынма кушма сүзләрнең үзенчәлекләре белән танышу. Сүз төзелешенә анализ ясарга өйрәнү. |
| ***Части речи***<br>**Сүз төркемнәре.**<br>***Имя*** | 34<br>6 | *Повторение о значении имен существительных, вопросах, формах, строении, их рли в предложении. Наблюдение того, что имена существительные могут в предложении быть сказуемым. Углубление знаний о именах существительных собственных и нарицательных,* |

| | | |
|---|---|---|
| ***существительное***<br>**Исем** | | *единственного и множественного числа. Углубленное изучение изменения имен существительных по падежам. Знакомство с твердым и мягким изменением имен существительных. Какие окончания бывают у имен существительных, которые не подчиняются законку сингармонизма. Познакомиться с изменением имен существительных по падежам. Возможность имен существительных употребляться в предложении в именительном падеже в виде подлежащего, сказуемого и дополнения. Значение творительного падежа , его функция в предложении.*<br>Исемнең мәгънәсе, сораулары, формалары, ясалышы, җөмләдәге урыны турында кабатлау. Исемнәрнең хәбәр булып килүләрен күзәтүләр.Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр, берлек һәм күплек сандагы исемнәр турында белемнәрен тирәнәйтү. Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнешен тирәнтен өйрәнү. Калын һәм нечкә төрләнеш белән танышу. Сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә кушымча ялгарга өйрәнү. Килеш кушымчаларының дөрес язылышы белән танышу. Баш килеш формасында исемнәрнең җөмләдә ия, хәбәр, иярчен кисәк була алуларына төшенү. Төшем килешенең мәгънәсе, җөмләдәге функциясе белән танышу. |
| ***Глагол***<br><br><br><br>**Фигыль** | 8 | *О глаголах, о его формах; формы будущего времени. Смысл глаголов повелительного наклонение, изменение их по числам и по лицам, правильное написание. Глаголы в предложении выполняют роль сказуемого, развитие знаний о иснонимах и антонимах у глаголов. Морфологический анализ глаголов.*<br>Хикәя фигыльнең билгеле үткән заман, нәтиҗәле үткән заман формалары, киләчәк заман формалары: билгесез киләчәк заман, билгеле киләчәк заман турында яңа мәгълүмат алу. Боерык фигыльнең мәгнәсе , зат-сан белән төрләнеше, боерык фигыльне куллану, дөрес язу турында белем алу. Фигыльнең җөмләдә хәбәр булып килүе, антоним һәм синоним фигыльләр турында мәгълүмат алу. Фигыльгә морфологик анализ ясау. |
| ***Имя прилагательное***<br><br><br><br><br><br><br>**Сыйфат** | 5 | *Имя прилагательное, его значение и использование в речи. Закрепление знаний о вопросах имен прилагательных. Познакомить с признаками имен прилагательных : цвет, вкус, форма, характер. Знакомство с степенями сравнения имен прилагательных. Только некоторые имена прилагательные имеют степень сравнения. В предложении имена прилагательные связаны с именем существительным и являютсяопределением. Имена прилагательные связаны с именем существительным. Роль имен прилагательных в предложении (является второстепенным членом или сказуемым), антонимы, синонимы. Морфологический анализ имени прилагательного.*<br>Сыйфат, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә куллану. Сыйфатның сорауларын ныгыту. Сыйфатның төс, тәм, форма, күләм, характер һ.б. билгеләрне белдерүе белән танышу. Сыйфат дәрәҗәләре белән танышу. Кайбер сыйфатларны гына дәрәҗәгә куеп була. Җөмләдә сыйфат исемне ачыклап килә һәм күбесенчә аергыч була. Сыйфатның исемгә бәйләнеп килүе. Сыйфатның җөмләдәге |

| | | |
|---|---|---|
| | | функциясе( аергыч, хәбәр), синоним һәм антоним сыйфатларны өйрәнү. Сыйфатка морфологик анализ ясау. |
| ***Местоимение***<br><br><br><br><br><br>**Алмашлык** | 4 | *Дать понятие местоимения. Изучение роли местоимения в предложении. Личные местоимения, их смысл и использование их в речи. Личные местоимения 1.2,3 лица, единственного и множественного числа, изменение их по падежам. Изменение личных местоимений по падежам, повтореие правильного правописания , изучение вопросительных местоимений. Вопросы падежей тоже являются вопросительными местоимениями. Вопросительные местоименя отвечают на вопросы какой, который, как, зачем.*<br>Алмашлык турында гомуми төшенчә бирү. Алмашлыкларның җөмләдәге ролен өйрәнү. Зат алмашлыклары, аларның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. I, II, III зат алмашлыклары, аларның берлек һәм күплек сан формалары, килеш белән төрләнешен өйрәнү. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, дөрес язылышын кабатлау һәм сорау алмашлыклары турында яңа мәгълүмат алу. Килеш сорауларының сорау алмашлыкларына керүен белү. Сорау алмашлыкларына тагын нинди, кайсы, ничек, ник, нигә, ничәнче кебек сүзләр керүе белән танышу. |
| ***Имя числительное***<br><br><br><br><br><br>**Сан** | 4 | *Имя числительное обозначает количество предметов, их порядок. Имя числительное не изменяется когда согласуется с именем существительным. В предложении может быть определением, сказуемым, а также когда используется без имени существительного может быть другими членами предложения. Познакомить с определением имени числительного, его значением, вопросами. Имя числительное связано с именем существительным , дать понятие количественных и порядковых числительных.*<br>Предметның исәбен, микъдарын белдерә торган сүз төркеме белән танышу. Санның исем белән кулланылганда төрләнмә вен төшенү. Җөмләдә аергыч, хәбәр һәм исемнән башка кулланылганда, җөмләнең бүтән кисәкләре дә була алуын аңлау. Санның билгеләмәсе (мәгънәсе, сораулары) белән танышу. Санның исемне ачыклап килүе, сан белән ачыкланып килгән исемнең саналмыш булуы, кайбер сан төркемчәләре(микъдар саннары, тәртип саннары) турында беренче мәгълүмат алу. |
| ***Наречие***<br><br><br><br>**Рәвеш** | 3 | *Наречие отвечает на вопросы как? когда? где? сколько? обозначает признак действия , признак признака. Наречие –самостоятельная часть речи, которая обозначает лексико-грамматический признак глагола, с морфологической точки зрения – не изменяется. С синтаксической точки зрения обозначает признак действия, признак признака, в предложении бывает обстоятельством.*<br>Рәвешнең ничек?, кайчан? Кая? Кайда? Никадәр? Күпме? кебек сорауларга җавап булып |

| | | |
|---|---|---|
| | | килүе, эш яки хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә торган сүз төркеме булуын аңлау. Мөстәкыйль сүз төркеме, лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерүен, морфологик яктан – төрләнмәвен, кайбер рәвешләрнең артыклык яисә чагыштыру дәрәҗәсендә килә алуларын аңлау. Синтаксик яктан - җөмләдә фигыльне, сыйфатны һәм рәвешне дә ачыклап килүен, төп синтаксик функциясе- хәл икәнлегенә төшенү. |
| ***Частицы*** **Кисәкчәләр** ***Союзы*** **Бәйлекләр** | 4 | *Роль частиц и послелогов в речи, понятие отрицания. Использование частиц в речи. Многие частицы бывают многозначными, их значение определяется от того, к какому слову они относятся, в каком месте стоят, от строения предложения, от интонации. Наблюдение того, как союзы используются с именами существительными и местоимениями в разных падежах Три группы союзов ( именительный падеж, дательный падеж, творительный падеж).* Кисәкчәләрнең сөйләмдәге роле-мәгънә, хис төсмерләрен, раслау, инкяр итүне белдерүе белән танышу. Аларны сөйләмдә дөрес куллану. Бик күп кисәкчәләрне күп мәгънәле була алуын һәм аларның мәгънә төсмерләре нинди сүзгә иярүләренә, кайсы урында килүләренә, җөмлә төзелешенә, аның интонациясенә карап үзгәрүен аңлау. Бәйлекләр сүзләрне бәйләгәндә, килешкә якын мәгънә белдерүен, үзләреннән алда килгән сүзнең билгеле бер килештә торуын, соравы белән танышу. Шуңа карап бәйлекләрне өч төркемчәгә аерырыга (баш, юнәлеш һәм чыгыш килеше) өйрәнү. |
| ***Словосочетание*** **Сүзтезмә** | 1 | *Объяснение различия словосочетания и сочетания слов, как они образуются, пути происхождения, наличие в словосочетаниях главного и зависимого слова.* Сүзтезмә һәм тезмә сүзләр арасындагы аерманы аңлау, сүзтезмәләрнең барлыкка килү юлларын ачыклау, сүзтезмәдәге иярүче һәм ияртүче сүз турында белемнәрне тирәнәйтү. |
| ***Предложение*** **Җөмлә** | 7 | *Закрепить знания о главных членах предложения, на какие вопросы они отвечают. Распространенные и нераспространенные предложения. Упражнения, как сделать из распространенного предложения нераспространенное и наоборот. Дать понятие определения, которое часто выражается именем прилагательным. Дать сведения о предложениях с однородными подлежащими, однородными сказуемыми, с однородными определениями. Однородные члены предложения, интонация перечисления, связь слов с помощью предлогов, знаки препинания между однородным членами предложения. Дать понятие обращения. Сложные предложения состоящие из 2-3 простых предложений. Сложносочиненные сложные предложения, знаки препинания в данных предложениях.* Ия белән хәбәр таба белүне, сорауларын куюны ныгыту. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр турында белемнәрне ныгыту. Җыйнак җөмләне тиешле сүзләр өстәп, җәенкеләндерә белү, җәенке җөмлә эченнән баш кисәкләрне аерып алу кебек күнегүләр эшләнелә**.** Аергыч турында |

| | | |
|---|---|---|
| | | мәгълүмат алу. Уметь находить определения в предложении. Җөмләдән иярчен кисәкләрне (аергычны) таба белү. Тиңдәш ияле, тиңдәш хәбәрле, тиңдәш аергычлы җөмләләр турында мәгълүмат алу. Тиңдәш кисәкләр арасында теркәгечләр булганда тыныш билгеләрен куярга өйрәнәләр.Эндәш сүзләр турында мәгълүмат алалар. Составында 2-3 гади җөмлә булган тезмә кушма җөмләләрне тиңдәш кисәкле гади җөмләләрдән аера һәм тикшерергә өйрәнү. Теркәгечләрне һәм тыныш билгеләрен куюны өйрәнү. |
| ***Текст. Развитие связной речи***<br><br>**Бәйләнешле сөйләм** | 8 | *Дать название тексту, определить часть текста и предложения, коррекция текста. Использование в речи текстов на определенную тему (описание, повествование, рассуждение), развитие монологической речи. Научиться отличать разные виды текстов. Изобразительные средства в тексте. Пересказ текста подробный и сокращенный. Поздравительная открытка, письмо , СМС. Упражнения для развития разговорной этики. Общение , с кем, когда, с какой целью. Уметь высказать свое мнение, привести доводы. Основные принципы при проведении беседы ( как начать разговор, включение в беседу, поддержание беседы , заинтересовать собеседника. Нормы литературной речи в повседневной жизни ( приветствие, прощание, извинение, благодарность, обращение с вопросом). Развитие монологической речи.*<br>Текстның темасын, төп фикерен, аның өлешләрен билгели белү осталыгын камилләштерәләр. Текстларның төрләре (хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү). Текстларны бер- берсеннән аера һәм төзергә өйрәнәләр. Текстта сурәтләү чаралары. Текстларның эчтәлеген кыскартып һәм тулысынча сөйләү. Котлау открыткасы, хат, СМС язарга өйрәнү. Сөйләм этикасына караган күнегүләр. Аралашу ситуациясен – аралашу кем белән, кайда, нинди максат белән башкарылуын аңлау. Үз фикереңне әйтү һәм аны дәлилләү. Әңгәмә үткәрүнең төп күнекмәләрен үзләштерү (сүз башлау, әңгәмәгә кушылу, аны дәвам итү, игътибарны җәлеп итү һ.б.). Уку, көндәлек аралашу шартларында тел әдәбе нормаларын үзләштерү (сәламләү, хушлашу, гафу үтенү, рәхмәтле булу, сорау белән мөрәҗәгать итү). Монологик сөйләм төзү күнекмәләрен камилләштерү. |
| ***Всего***<br>**Барлыгы** | **68** | |